**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 30 сентябрендәге 4126 номерлы карары**

**Казан шәһәре Идел буе районының**
**Авангард һәм Сормово урамнары чикләрендәге**
**территорияне планлаштыру проектын раслау турында**

«Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе гаризасы нигезендә, территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьяларына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру буенча документларны әзерләү, килештерү, раслау, гамәлдә булу вакытын озайту, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнары, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карарына, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 18 июнендәге 1523 номерлы «Казан шәһәренең Идел буе районындагы Авангард һәм Сормово урамнары чикләрендә территорияне планлаштыру документларын әзерләү турында»гы карарына таянып, 2024 елның 25 июленнән алып 2024 елның 15 августына кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышу нәтиҗәләрен исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. Казан шәһәренең Идел буе районындагы Авангард һәм Сормово урамнары чикләрендә территорияне планлаштыру проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» (www.docskzn.ru) челтәр басмасында бастырып чыгарырга.

3. Билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми

порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Кушымта
Казан шәһәре Башкарма комитетының
2024 елның 30 сентябрендәге
4126 номерлы карары белән
расланды

**Казан шәһәре Идел буе районының**
**Авангард һәм Сормово урамнары чикләрендәге**
**территорияне планлаштыру проекты**

Казан шәһәре Идел буе районының Авангард һәм Сормово урамнары чикләрендәге территорияне планлаштыру проектының (алга таба – планлаштыру проекты) төп өлеше түбәндәге проект материалларыннан тора:

I. Кызыл линияләрне, планлаштыру структурасының гамәлдәге һәм планлаштырыла торган элементлары чикләрен, капиталь төзелеш объектларын урнаштыру планлаштырыла торган зоналар чикләрен күрсәтеп, территорияне планлаштыру сызымы.


II. Кызыл линияләр күрсәтелгән, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге теркәлгән территорияне планлаштыру проекты сызымы.

III. Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмә.

IV. Территорияне план буенча үстерүнең чираты турында нигезләмә.

Билгеләнән торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материал булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

I. Чертеж планировки территории с указанием красных линий, границ существующих и планируемых элементов планировочной структуры, границ зон планируемого размещения объектов капитального строительства





УСЛОВНЫЕ ОБОЗНАЧЕНИЯ

- граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проект планировки территории
- граница элемента планировочной структуры
- устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- действующая красная линия улично-дорожной сети
- действующая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- граница планируемого технического коридора инженерных коммуникаций и сооружений
- 8 — порядковый номер зоны размещения
- 2 — вид зоны размещения объектов капитального строительства
- 0.2 — площадь зоны размещения, га
- 3.7.2 — коды видов разрешенного использования
- 5 — зона планируемого размещения объектов культового назначения
- 11 — зона существующего размещения объектов инженерной инфраструктуры
- 11 — зона планируемого размещения объектов инженерной инфраструктуры
- 20 — зона размещения озелененных территории общего пользования
- 21 — зона размещения объектов улично-дорожной сети
- 1 — здание мечети

М 1:1000

II. Чертеж проекта планировки территории с указанием красных линий




Условные обозначения

- граница территории, в отношении которой осуществляется подготовка проект планировки территории
- красная линия — устанавливаемая красная линия улично-дорожной сети
- красная линия — действующая красная линия улично-дорожной сети
- красная линия — отменяемая красная линия улично-дорожной сети
- КЛ ТОП — устанавливаемая красная линия территории общего пользования (за исключением улично-дорожной сети)
- 5 — условные номера характерных точек устанавливаемых красных линий.

**Примечание:**

Ведомость координат характерных точек устанавливаемых красных линий приведена в Приложении 1

**Сокращения надписей, принятые на чертеже**

1. КЛ ТОП - красная линия озеленения территории общего пользования

М 1:1000

## III. Капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, территорияне план буенча үстерү характеристикалары, шул исәптән төзелешнең тыгызлыгы һәм параметрлары, социаль, транспорт хезмәте күрсәтү һәм инженерлык-техник яктан тәэмин итү системаларын үстерү характеристикалары турында нигезләмә

### 1. Территорияне планлаштыру проектының чикләре

Проектлаштыру территориясе Казан шәһәренең Идел буе районында урнашкан.

Әлеге проект чикләренә Урта Кабан күле ярында урнашкан, көнбатыштан Авангард урамы белән чикләнгән территория керә.

### 2. Территория характеристикалары

Территорияне планлаштыру проектының мәйданы 0,5 га тәшкил итә.

Планлаштыру проекты белән түбәндәгеләр каралган:

- дини билгеләнештәге объектны (мәчетне) план буенча урнаштыру зонасы,

- гомуми кулланыштагы яшелләндерелгән территорияләр зонасы;

- урам-юл челтәре зонасы;

Инженерлык инфраструктурасы объектларын план буенча урнаштыру зонасы.

### 3. Транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерү характеристикалары

Территорияне планлаштыру проекты белән 77 м озынлыктагы җирле әһәмияттәге урамнар төзү каралган.

### 4. Инженерлык-техник тәэмин итү системасын үстерү характеристикалары:

4.1. Су белән тәэмин итү.

Әлеге төзелештә хуҗалыкта куллану һәм эчү өчен тәүлеклек су чыгымы 11,16 куб.м/тәүлек тәшкил итә, елның җәйге вакытында территориягә сибү өчен су чыгымы – 1,66 куб.м/тәүлек.

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең 2024 елның 11 мартындагы 6622/06/16-29 номерлы техник шартлары нигезендә Авангард урамы буенча Ø315 мм лы суүткәргечтән планлаштыру проекты территориясен су белән тәэмин итү каралган.

Су белән тәэмин итү системасы хуҗалык һәм янгын сүндерү өчен булган ихтыяҗларны берләштереп кабул ителә.

Проектлана торган челтәрләрнең гомуми озынлыгы – 0,03 км. Проектлана торган суүткәргеч челтәрләренең күләме 2,3 метрдан 3,0 метрга кадәр җитәчәк.

Тышкы янгын сүндерүгә суның максималь сарыф ителүе 15,0 л/тәүлек (мәчет, V=6550,4 куб.м), бер үк вакытта килеп чыккан янгыннар саны – 1.

Эчке янгын сүндерүгә суның чыгымнары – 2,5 л/сек (10.13130 номерлы «Янгынга каршы көрәш системалары. Эчке янгынга каршы суүткәргеч. Проектлау нормалары һәм кагыйдәләре» кагыйдәләр җыелмасы).

4.2. Су чыгару.

Карап тикшерелә торган территориядә агынты суларның тәүлеклек чыгымы тәүлеккә 3656,4 куб.м тәшкил итәчәк.

«Водоканал» муниципаль унитар предприятиесенең 2024 елның 11 мартындагы 6622/06/16-29 номерлы техник шартлары нигезендә проектлана торган төзелешләрдән көнкүреш агынты суларны читкә чыгару өчен, гамәлдәге канализация коллекторына тоташтырып, көнкүреш канализациясе челтәрләрен проектлау күздә тотыла.

Проектлана торган канализация челтәрләренең гомуми озынлыгы – 0,08 км. Үзагышлы канализация челтәрләре 1,6-1,8 м тирәнлеккә салынган.

4.3. Яңгыр канализациясе.

Җир өсте суларының территориядән агып чыгуы 34,52 л/сек тәшкил итәчәк.

Яңгыр канализациясе Казан шәһәре Башкарма комитеты Тышкы төзекләндерү комитетының 2024 елның 7 мартындагы 02-41/612 номерлы техник шартлары нигезендә каралган.

Проект белән төзелеш территориясе янында урнашкан яңгыр канализациясенең ø500 мм тимер-бетон торбаларын, алга таба рельефка чыгарып, полиэтилен торбаларга күчереп салырга тәкъдим ителә.

4.4. Җылылык белән тәэмин итү.

Проектлана торган төзелешкә исәпләүләр нигезендә җылыга ихтыяҗ 0,65 МВт (0,56 Гкал/сәг) тәшкил итәчәк.

Мәчетне җылылык белән тәэмин итү өчен пар казаннары 0,35 МВт (1 данә) һәм 0,30 МВт (1 данә) булган БМК-1 блоклы-модульле котельный төзү каралган.

Котельныйның егәрлеге – 0,65 МВт (0,56 Гкал/сәг). Җылылык үткәргеч торбаларның параметрлары – 110º-70ºС.

Проектта проектлана торган БМК-1 җылылык челтәрен салу каралган. Җылылык үткәргечләр – 2Ø133 мм.

ОДК системасы белән җиһазландырылган, полиэтилен тышчалы пенополиуретаннан торган ике торбалы җылылык челтәрләрен каналсыз салу күздә тотыла.

Җылылык челтәрләренең уртача тирәнлеге – 1,8 м.

4.5. Газ белән тәэмин итү.

Блоклы-модульле котельныйга газ сарыф ителүе – 77,7 куб.м/сәг.

Уртача басымлы Ø110x10 газүткәргечен салу каралган, озынлыгы – 55 м.

4.6. Электр белән тәэмин итү.

«Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыятенең 2023 елның 19 декабрендәге К/Тг/ТП/23-918 номерлы хаты нигезендә туклану үзәге булып «Искож» подстанциясе кабул ителә.

Исәпләүләр нигезендә 76,79 кВт электр куллануны тәшкил итә.

Территорияне төзү буенча эшләнгән планлаштыру карарларын исәпкә алып, түбәндәге чаралар каралган:

- китерә торган КЛ 10 кВ төзү – 1,1 км;

- ТП-1 – 2×100 кВ·А төзү (кертеп төзелгән трансформатор подстанциясен урнаштырырга мөмкин);

- ВРУ-0,4 кВ урнаштыру;

- өч фазалы ток кабул итү җайланмаларын тулы булмаган режимда 0,4 кВ га кертүдә саклану рәвешендә сүндерү, җиргә тоташтыру (бер фазалы ток кабул итү җайланмаларын артык көчәнештән саклау);

- электр белән тәэмин итүнең тышкы челтәрендә көчәнешнең технологик яктан кимүе һәм кыска вакытлы өзеклекләр килеп чыкканда, кайбер ток кабул итү җайланмалары өчен өзлексез туклану агрегатларын урнаштыру.

Электр тапшыруның җир асты кабель линияләре буйлап саклау зонасы кырый кабельләрдән горизонталь буенча 1 м ераклыкта линиянең ике ягында

торган параллель вертикаль яссылыклар белән чикләнгән җир кишәрлеге рәвешендә урнаштырыла.

**5. Урам-юл челтәре өчен мәҗбүри алынырга (резервланырга) тиешле җир кишәрлекләре исемлеге**

| № т/б | Объектның кадастр номеры, билгеләнеше, исәп номеры | Җир участогының мәйданы, кв.м | Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре | Мәҗбүри алу |
|---|---|---|---|---|
| | 16:50:080305:5 | 366 кв.м | Урам-юл челтәре (код 12.0.1) | Өлешчә мәҗбүри алу |

## IV. Территорияне план буенча үстерү чираты турында нигезләмә

Проектлаштыру һәм төзелеш этаплары

1. Проект документларын башкару һәм мәчетне төзү;
2. Инженерлык коммуникацияләрен салу;
3. Территорияне төзекләндерү.

_______________